**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№113** **«29» октябрь 2018 ел**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 134 номерлы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 32 бүлеге нигезендә, шулай ук "Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 134 номерлы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 12 сентябрендәге 170 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктта:
а) 2 пунктчада «фатирлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;
б) 3 пунктчада «торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә.
1.2. 3 пунктчада «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.
3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

**Совет рәисе** **Т.В. Попова**